РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**14 июнь 2023 ел** **Чистай шәһәре** **№ 23/10**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы Советының
«Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын)
оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы
Нигезләмәне раслау хакында»гы
2018 елның 18 июлендәге
35/5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2018 елның 18 июлендәге 35/5 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (Чистай муниципаль районы Советының 2019 елның 6 февралендәге 41/2 номерлы, 2019 елның 23 маендагы 44/5 номерлы, 2021 елның 20 октябрендәге 10/9 номерлы, 2022 елның 27 маендагы 15/6 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 3 пунктының икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2 6 статьяда:

1.2.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. әгәр гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса, гавами тыңлаулар уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, шул исәптән районның рәсми сайтында урнаштырылырга,

шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый акт проектын халык алдында тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәрен шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган искәрмәләр һәм тәкъдимнәр муниципаль берәмлек халкы тарафыннан «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик үзара бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмати системасын кулланып авторизацияләгәннән соң, бердәм порталны кулланып кертелә. Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын һәм гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүматны бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана. Күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.»;

1.2.2. 1.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1.1. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарыла, Чистай муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.»;

1.3. пункт 8 статьи 7 изложить в следующей редакции:

«8. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәгә оештыру комитеты рәисе һәм секретаре имза сала һәм гавами тыңлаулар уздырган көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Чистай муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.»;

1.4. 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. «12 статья. Муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын, гавами тыңлауларны карау үзенчәлекләре

Генераль планнар проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларына, территорияне планлаштыру проектларына, территорияләрне ызанлау кагыйдәләренә, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектларына кагылышлы мәсьәләләр, күрсәтелгән документларның берсенә үзгәрешләр кертүне, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның рөхсәт ителгән төренә яисә рөхсәт бирү турындагы карарларның проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын

реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарларның проектларына, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү мәсьәләләренә, җирдән файдалану һәм төзелеш объектлары расланмаган кагыйдәләр булмаганда, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, иҗтимагый фикер алышуларга чыгарылырга мөмкин.»;

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә билгеләнгән тәртиптә карарны бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов